ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САЛАУСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ САЛАВЫЧ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
«28» гыйнвар 2022 ел

КАРАР
№ 2

## Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә бирелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә бирелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 6964,68 сум итеп билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә бирелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2021 елның «29» гыйнвар 1 нче номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге Башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы: Р.К.Латипов

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы Салавыч
авыл җирлеге
башкарма комитетының
2022 елның 28 гыйнвар 2нче
номерылы карарына
1 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегендә
җирләү буенча хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3064,83 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка алып бару | 864,43 |
| 4. Җирләү (каберләр казу һәм күмү) | 3035,42 |
| Барлыгы | 6964,68 |

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Салавыч  авыл җирлеге
башкарма комитетының
2022 елның 28 гыйнвар 2 нче
номерылы карарына
2 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы

Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегендә

җирләү буенча хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Кәфенләү | 263,95 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 2800,88 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка алып бару | 864,43 |
| 5. Җирләү (каберләр казу һәм күмү) | 3035,42 |
| Барлыгы | 6964,68 |